ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2021 елның 6 декабре** **Чистай шәһәре** **№ 737**

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 30 июлендәге 426 номерлы
карары белән расланган җир эшләрен
башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ
регламентына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Региональ (республика) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына «Чистай тарихи үзәге» истәлекле урынын кертү һәм аны Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарих һәм мәдәният ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертү турында» 2013 елның 12 ноябрендәге 869 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 426 номерлы карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.7.1 пунктының 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) капиталь төзелеш объектын технологик тоташтыру буенча эшләр башкарган очракта, җир кишәрлегеннән файдалануга ризалык (рөхсәтнамә) булмау (челтәр оешмалары тарафыннан башкарыла торган энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыру очракларыннан тыш), төзелешкә рөхсәтнамә булмау.»;

1.2. 2.5.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле «д» пунктчасын өстәргә:

«д) "Чистай тарихи үзәге" истәлекле урыны" төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре һәм режимы чикләрендә эшләр

башкарганда мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы Комитеты белән килештерү.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов